**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 6 мартындагы 597 номерлы карары**

# «Рубин» һәм «Спартак» командалары арасында футбол матчын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

«Рубин» һәм «Спартак» командалары арасында футбол матчын әзерләү һәм уздыру чорында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы «Рәсми спорт ярышларын уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»гы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чараларының хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә вакытлыча туктату тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда 2025 елның 9 мартында 18.30 сәгатьтән алып 22.30 сәгатькә кадәрге вакыт аралыгында Казан шәһәре урам-юл челтәренең түбәндәге участокларында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә:

- Чистай урамында, А.Бичурин урамыннан Ямашев проспектына кадәр участокта;
- Чистай урамында, Ямашев проспектыннан Адоратский урамына кадәр участокта;
- Ямашев проспекты буенча, Адоратский урамыннан Себер Тракты урамына кадәр участокта;
- Гаврилов урамындагы дублер юлда, Маршал Чуйков урамыннан Чистай урамына кадәр участокта;

- Академик Арбузов урамында, Журналистлар урамыннан Ямашев проспектына кадәр участокта;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары (Р.Х.Шәмсетдинов), Совет районы (Р.Р.Фәтхетдинов) администрацияләре белән берлектә юлларны йөк техникасы яисә таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) күрсәтелгән урам-юл челтәре участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**